**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы**
**Савруш авыл җирлеге башкарма комитеты**

# КАРАР

№ 3 01.02.2016 ел

2016 елга Аксубай муниципаль районы
«Савруш авыл җирлегендә» коррупциягә
каршы тору чаралар планын раслау турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 25.12.2008 ел, № 273-ФЗ Федераль закон, « Коррупциягә каршы көрәш буенча Милли стратегия» Россия Федерациясе Президентының 13.04.2010 ел, № 460 Указы, «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында» 04.05.2006 ел, Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм Савруш авыл җирлеге эшчәнлегенең профилактика буенча нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Савруш авыл җирлеге башкарма комитеты коррупцион хокук бозулар турында карар чыгара:

1. Кушымта нигезендә «Савруш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә коррупциягә каршы чаралар планын расларга.
2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, җәмәгать урыннарында һәм Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында игълан итәргә: http://aksubayevo.tatarstan.ru
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Аксубай муниципаль районы
Савруш авыл җирлеге
Җитәкчесе: А.Г.Кузьмин.

Кушымта
Савруш авыл җирлеге
башкарма комитеты карарына
№ 3 01.02.2016 ел.

**Чаралар планы**
**Савруш авыл җирлегендә коррупциягә каршы көрәш буенча 2016 елга**

| Бүлекләр һәм пунктлар | чара | Башкару вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| **1.Коррупциягә каршы көрәш эшчәнлеген хокукый җайга салуны камилләштерү һәм оештыру ягыннан тәэмин итү өлкәсендә чаралар** | | | |
| 1.1. | Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча муниципаль хокукый актларны Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары үзгәрешләренә һәм өстәмәләренә туры китерү | Ел дәвамында | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 1.2. | Коррупциягә каршы экспертиза үткәрү:<br>-муниципаль норматив хокукый актлар проектлары;<br>- муниципаль норматив хокукый актлар; | Ел дәвамында | Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Юридик бүлек башлыгы Габдрахманов М. А. |
| 1.3. | Коррупциягә каршы көрәш буенча Аксубай муниципаль районы башлыгы каршындагы комиссия белән хезмәттәшлекне тәэмин итү | Ел дәвамында | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 1.4. | Коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә хокук саклау органнары белән хезмәттәшлекне тәэмин итү | Ел дәвамында | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 1.5. | Расланган административ регламентлар нигезендә муниципаль хезмәтләр күрсәтү сыйфаты турында халык арасында мониторинг (сораштыру) үткәрү | даими | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 1.6. | Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүне оештыруны камилләштерү. Гражданнарны кабул итү графигын раслау | даими | Башкарма комитет җитәкчесе, Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары |
| 1.7. | Җирле үзидарә органында коррупция фактлары турында гражданнарның шикаятьләрен һәм мөрәҗәгатьләрен анализлау һәм күрсәтелгән фактларны тикшерүне оештыру (булганда) | Кварталга 1 тапкыр | Башкарма комитет җитәкчесе |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **2.Кадрлар сәясәтен камилләштерү буенча чаралар** | | | |
| 2.1. | Коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны һәм бурычларны үтәмәү, муниципаль хезмәткәрләргә кагылышлы чикләүләрне бозу очраклары буенча тиешле хокукый җаваплылык чараларын куллану һәм билгеләнгән тәртиптә тикшерүләр үткәрү. Эш башкаруны контрольдә тотуны көчәйтү. | Үтәмәү фактын билгеләгәндә | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 2.2. | Муниципаль хезмәткәрләр өчен хезмәт тәртибенә һәм хезмәт этикасына таләпләрне, коррупциячел хокук бозулар һәм җинаятьләр өчен административ һәм җинаять җаваплылыгы мәсьәләләрен аңлату буенча киңәшмәләрдә катнашу | Ел дәвамында | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 2.3. | Муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны һәм бурычларны үтәү буенча оештыру, аңлату һәм башка чаралар комплексын, шул исәптән бүләкләр алуга кагылышлы чикләүләрне гамәлгә ашыру | Ел дәвамында | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 2.4 | Муниципаль хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре һәм чыгымнары турында мәгълүматларны вакытында тутыру һәм тапшыру эшен оештыру | 2016 елның 30 апреленә кадәр | Башкарма комитет җитәкчесе |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **3. Муниципаль заказны урнаштыру өлкәсендә эшчәнлекне камилләштерү буенча чаралар** | | | |
| | | | |
| 3.1. | Сатуларны планлаштыру хисабына сатып алулар планын үтәүне тәэмин итү, еллык план-графикны раслау (мөмкин булган үзгәрешләрне исәпкә алып) һәм аны «Интернет»челтәрендә рәсми сайтка урнаштыру | Ел дәвамында | Бухгалтер СП |
| **4. Халыкка мәгълүмат бирү буенча чаралар** | | | |
| 4.1 | Авыл җирлеге территориясендәге учреждениеләрдә һәм оешмаларда коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча аңлату эшләре алып бару | Ел дәвамында | Глава СП, руководители учреждений и организаций (по согласованию) |
| 4.2. | Аксубай муниципаль районы сайтында авыл җирлегенең, мәгариф учреждениеләренең һәм «Интернет» челтәренең мәгълүмат стендларында коррупциягә каршы көрәш буенча кабул ителә торган муниципаль хокукый актларны урнаштыру | Ел дәвамында | Заместитель Руководителя Исполнительного комитета |
| 4.3. | Хуҗалык китапларыннан өземтәләр бирүне контрольдә тотабыз. | Ел дәвамында | Глава СП |
| 4.4. | Мәдәният һәм мәгариф бүлеге белән берлектә халык арасында коррупциягә каршы көрәш буенча аңлату эшләре алып бару чаралары. Халыкара коррупциягә каршы көрәш көненә багышланган түгәрәк өстәлләр , әңгәмәләр уздыру. » хәбәрдарлык тартмалары " н гражданнарның язма мөрәҗәгате өчен учреждениеләрдә урнаштыру. | Квартал саен | Глава СП, руководители учреждений и организаций (по согласованию) |